БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 15 » сентябрь 2018 ел № 300

Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондыннан файдалануга һәм аны саклауга, әлеге фондның торак урыннарының билгеләнгән санитария һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, законнарның башка таләпләренә туры килүенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында административ регламентны раслау хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы нигезендә, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, “Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында” 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, “Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне башкаруның административ регламентларын эшләү һәм раслау турында” 2013 елның 23 апрелендәге 275 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондыннан файдалануга һәм аны саклауга, әлеге фондның торак урыннарының билгеләнгән санитария һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, законнарның башка таләпләренә туры килүенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында административ регламентны кушымта нигезендә расларга.
2. “Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондыннан файдалануга һәм аны саклауга, әлеге фондның торак урыннарының билгеләнгән санитария һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, законнарның башка таләпләренә туры килүенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында административ регламентны” 2016 елның 11 июлендәге 181 номерлы Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
Җитәкчесе Р.И.Шакиров